ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫң
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10» декабря 2025 ел. № 340

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Норматив хокукый актларны гамәлдәге закон таләпләренә туры китерү максатында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

- 2021 елның 29 июлендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентын раслау турында»гы 238нче номерлы карар;

- 2021 елның 29 июлендә кабул ителгән «Бәйге үткәрмичә, түләүле нигездә арендага яки милеккә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентын раслау турында»гы 240 нче номерлы карар;

- 2016 елның 24 августында кабул ителгән «Мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтү административ регламентларын раслау турында»гы 385 нче номерлы карар;

- 2013 елның 14 мартында кабул ителгән "Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, гражданнарга (түләүле яки түләүсез шартларда) опека (попечительлек) билгеләү яки опекун (попечитель) булу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында"гы 74 нче номерлы карар;

- 2021 елның 29 июлендә кабул ителгән «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендага алынган мөлкәтне милеккә алырга өстенлекле хокукларны гамәлгә ашырганда, алар тарафыннан арендага алынган күчемсез милекне бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентын раслау турында»гы 251 нче номерлы карар;

- 2016 елның 21 сентябрендә кабул ителгән «Спорт бүлеге турында нигезләмәне һәм спорт бүлеге башлыгының вазифаи инструкциясен раслау турында»гы 442 нче номерлы карар;

- 2022 елның 20 июлендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында административ хокук бозулар турында протоколлар төзүгә вәкаләтле вазифаи затлар исемлеге турында»гы 162 нче номерлы карар.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) «Интернет» челтәрендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Вакытлыча Башкарма комитет җитәкчесе вазифасын башкаручы** **Р.Н. Бадахшин**